ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2026 г. Агрыз № 46

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 15 мартындагы 25 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль законы һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 15 мартындагы 25 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның икенче абзацында «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктның икенче абзацында «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

- карарның 1 нче кушымтасы аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы» Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында рәсми сайтта урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге";

- 2 пунктның өченче абзацында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм аларга буйсынучы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы

Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.Н. Халиковка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов